
9/90
Ноябрь

ISSN 0868-4545

Салават күпере



ВАКЫТСЫЗ УЯТКАН

Мәзәк

— И, әбием, нигә син мине шундый тәмле төш күргәндә уяттың инде, ә?— диган бер бала.

— Мин бит синең тәмле төш күргәнеңне белмәдем лә-баса!— диган әбисе.

— Ничек белмисең инде?! Син бит минем белән янәшә чәк-чәк ашап, тәмле кәнфит белән чәй эчеп утырдың! — диган бала.






Табышмак әйтәм - җавабын тап!

Сыер нигә ята?

Утыра алмаганга.

Каз судан чыккач нишли?

Коры җирга баса.





Рәссам Й. ВӘЛИӘХМӘТ

Суык

Такмаза

Булса суык
Шиңә куык,
Булмый куып,
Колак уып.
Билне буып,
Кулны уып
Утыру белән
Бетми суык.







Песи, кая барасың?

Әйтешү

— Песи, кая барасың?
— Әбиләргә барамын.
— Анда сиңа ни тия?
— Ике калак май тия.
— Аны кая куярсың?
— Мич астына куярмын.
— Пычранса нишләрсең?
— Суга төшеп юармын.
— Төшеп китсәң нишләрсең?
— Талга ябышып чыгармын.
— Талың купса нишләрсең?
— Акырып-бакырып җы-
лармын.





© «Салават күпере», 1990 ел



ШҮРӘЛЕ

ТАТАР ХАЛЫК ӘКИЯТЕ

Әүвәле берәү урманда утын кисә икән, аның янына бер шүрәле килеп чыккан ди. Шүрәле аңа:

— Син ни атлы?— дигән. Ул кеше:

— Мин Былтыр атлы,— дигән. Шүрәле кешегә:

— Әйдә, кети-кети уйныйк әле,— дигән.

— Ярар, элгәре менә бу тумранны ярыйк әле, аннары уйнарбыз,— дигән кеше.

Кеше тумранга балта белән чапкан икән, тумран азрак ярылган. Шуннан соң бу кеше шүрәлегә әйткән:

— Мин икенче чапканчы, син шунда бармагыңны кыстырып торсана,— дигән. Шүрәле бармагын ярыкка куйган икән, кеше балтасын алгач, ул шунда кысылган да калган. Кеше балтасын алган да качкан. Шүрәле шыр-шыр кычкыра башлаган ди:

— Бармагымны Былтыр кысты, Былтыр кысты!— дип.

Менә аның янына бүтән шүрәлеләр җыелган, аннан:

— Кем кысты?— дип сорыйлар икән. Ул:

— Былтыр кысты,— дип әйткән ди. Алар аңа әйткәннәр ди:

— Быел кысса, табар идек, былтыр кыскач, каян табасың,— дигәннәр ди.

— Соң син былтырдан бирле ник кычкырмый тордың,— дигәннәр, ди. Шүрәле аларга авыртуыннан юньләп әйтә дә алмаган ди.

Ул шүрәле, бармагы кысылган көе тумранын аркасына күтәреп, әле дә шулай кычкырып йөри ди.

Рәссам Ф. МУЛЛАХМӘТ



...чы-че, әле, зинһар өчен...





Сөйләшә белеп сөйләшмәсәң, үпкә-сапка чыга да тора. Син: «Инде хәзер миңа бир!» — дидең. Азат: «Юк, үзем уйныйм», — диде. Син: «Саран...» — дип үчекләдең. Азат: «Ә үзең соң, үзең...» — дип үчләште. Шунда «биреп тор әле», я «биреп торчы» дигән булсаң... Бирә иде! Һичшиксез! Ышанмыйсыңмы? Ә син тикшереп кара...

Нинди кыска сүз — ӘЛЕ. Үзе бик көчле сүз. ЧЫ белән ЧЕ сүз дә түгел, кушымча гына. Алар да көчле. Шуларны кушып сөйләшсәң, үтенечең җавапсыз калмас, «Юк!» — дигән җавап та алмас.

Әгәр үтенечең зур икән, кешегә мәшәкать тудыра икән, «зинһар өчен» не кушып җибәрү дә зыян итми: «Зинһар өчен барыйк, әнием!», «Ачып биregезче, зинһар өчен»...

Сиңа үтенече төшкән кешегә сүзсез генә булышып куярга ярый. Инде «рәхәтләнеп» дип әйтеп тә җибәрсәң, гозерле кешенең тагын да күңеле була. «Эшлибез аны, рәхәтләнеп эшлибез», — дидең бит син шул бер сүз белән. Аннары үзең дә бик тәмле бер сүз ишеттең. Анысы турында — алдагы санда.

Рәссам А. МЕХОВНИКОВ



Ркаил ЗӘЙДУЛЛА

КАЗ ӨМӘСЕ

Атлар чаба урамнан,
Чалулый чаналары.
Җилдерәләрме белеп,
Белмичә чабалармы?

Каз өмәсе ич бездә.
Карда — каз түшкәләре.
Саклаган бәбкәләрем
Исемә төшкәләрме?

Каурый-каурый кар ява.
Җырлары апаларның
Тылсымлыдыр...
Бикләре
Коела капкаларның.

Җиргә иңәме җырлар,
Һаваларга ашамы?—
Тальян тавышларында
Казлар каңгылдашканы...

Рәссам С. ИБРАҺИМОВА




ПЕСИ, ПЕСИ ПЕСКӘЕМ

Минем нәни пескәем бар,—
Йомшак йонлы дускаем.
Үскән саен матурая,
Шөгыле арта көн саен.
Әбиемнең йомгагына
Ул һич тынгылык бирми.
Идән буйлап тәгәрәтеп,
Уйнап, куышып йөри.
Алдыма менеп ята да
Мыраулап күзен кыса.
Кыштырдаган тавыш килсә,
Шундук почмакка поса.
Иркәләнеп ярattыра,
И хәйләкәр пескәем...
Бигрәкләр дә назлы инде
Минем якын дускаем.




Лиана ӘМИРХАНОВА шигыре
һәм рәсеме.
Казан.






ГАҖӘП ХӘЛ

(Ышансаң ышан, ышанмасаң ышанма)

Безнең әбиләрнең бер песие бар. Кечкенә чакта ул тышта үскән. Шуңа күрә кыргыйдыр инде ул. Суык чакларда да өйгә керми. Гел тышта яши. Хәзер картайган инде. Ләкин шулай да бик батыр.

Беркөнне ишегалдында дүрт эт, күмәкләшеп, сугыша иде. Шулчак, ук кебек атылып, аларның араларына безнең песи килеп керә. Теге дүрт эт, дүрт якка китеп, күздән югала. (Әле җитмәсә, бер эт овчарка була). Шуннан бирле, этләр сугыша башласа, араларына песине генә җибәрәбез. Күселәргә, тычканнарга көн юк инде, әйтеп тә торасы юк.

Гөлназ ГАЛЛӘМОВА, 9 яшь.
Азнакай.


СӨЕНЕЧ

Безнең Иркә, иртән торгач,
Рәхәтләнеп юына.
Юынгачтын, тәмләп кенә,
Сөт-май белән туена.

«Песиебез чиста»,— диеп
Аркасыннан сөябез.
«Бүген безгә кунак килә,*
Кунак килә!»— диябез...

Алсу ГАЙНЕТДИНОВА, укучы.
Пермь. Ишим авылы.

**Халыкта «Песи юынса, өйгә кунак килә» дигән ырым-ышану бар. (Ред. искәрмәсе).*



Алия ИСХАКОВА рәсеме. 10 яшь.
Түбән Кама.



Күңелеңдә булса

Кадерле балалар!

Бу сәхифәдә аңлашылмаган урыннар очраса, сезгә абый-апаларыгыз, әти-әниләрегез, әби-бабайларыгыз ярдәмгә килер дип ышанабыз.

СЫЕР СҮРӘСЕ — 2 НЧЕ СҮРӘ

253 нче аять. Әй, иман китергән адәмнәр! Сату-алу да булмаган, файда бирә торган дуслык та булмаган, Аллаһы тәгаләнең рөхсәтеннән башка кемнедер яклау да мөмкин булмаган көн килмәс борын, Без ризыкландырган, ягъни Без өлеш чыгарган нәрсәдән Алла юлына сарыф кылыгыз!

Кяфирләр, ягъни алласызлар Аллаһы тәгаләнең әмерен үтәмәү сәбәпле — мәрхәмәтсезләр.

253 НЧЕ АЯТЬКӘ АҢЛАТМА.

Аллаһы тәгалә кешеләрне яхшылык, изгелек кебек сыйфатларга ия итте.

Кешеләр шул сыйфатлардан башкаларга да өлеш чыгарырга тиешле.

Мөселман кешенең кыямәт көненә кадәр ярдәм кирәк кешеләргә эчкерсез, ягъни эшләгән изгелеге өчен берни дә өмет итмичә булышлык итүе — изге бурыч санала.

Бу сыйфатлардан өлеш чыгармаган кяфирләр, ягъни алласызлар мәрхәмәтсез, шәфкатьсез була.

Сәхифәне Әнвәр ХӘЙРИ әзерләде.

Рәссам Н. ӘЛМИЕВ





Гали, Вәли һәм башкалар

Һәр милләттә иң еш очрый торган исемнәр була. Мәсәлән, урыс халкында — Ваня (Иван), немецларда Ганс, Фриц, грузиннарда — Гиви, латышларда — Янис, татарларда — Гали, Вәли (элгәреге елларда)... Дөрес, соңгы вакытларда бездә Айрат, Азат исемнәре ешаеп китте.

Бер иш эти-әниләр сөекле улларына һәм кызларына башка милләт исемнәре — Марсель, Виктория, Роберт, Гуля, Эдуард — куша, ә кайберәүләр үзләре «уйлап чыгарган» исемнәрне балаларына «бүләк» итәләр: Рафакил, Гизил, Нурфән...

Күңелгә ятышлы, сирәк очрый торган исемнәрне кушучы эти-әниләр дә бар. Чыңгыз, Сөембикә (нугайларда — Сөенбикә) исемнәрен шундый исемнәр рәтенә куярга мөмкин.

СӨЕМБИКӘ — *болгар-татар сүзе; сөемле, сөекле бикә, сөекле кыз дигән мәгънәне аңлата.*

ЧЫҢГЫЗ — *монгол сүзе; бөек, көчле, кодрәтле дигән мәгънәне белдерә.*

ЯРАМАГАН ТАГЫ...

Мәзәк



Рәссам А. Утәгән



Бер агай яңа туган малаена Зузик дип исем кушкан ди. Бу хәбәрне ишеткән кешеләр:

— Нигә улыңа андый исем куштың, эт исеме түгелме соң ул?— дип сораган ди әлеге агайдан.

— Һи, ярамаган тагы бала-чагага!— дигән ди, имеш, агай.

ӘЛИФБА


Ее

егет
ел
елга
ефәк
елъязма

СУ БУЕ

Ай су буе, су буе,
Ярында таллар куе,
Талларда кошлар туе,
Кайтып булмый көн буе.

ӘЙДӘГЕЗ, УЙНЫЙБЫЗ!









Безнең рәссам әллә үзе бераз буталып киткән, әллә сезне буташтырырга уйлаган, рәсемнәрне тиешле урынга ясамаган. Рәссамның ялгышын төзәтегез әле. Юк-юк, журнал кисеп түгел, менә болай. Башта рәсемнәрдәге әйберләрнең исемнәрен шакмакларга дөрес итеп язып чыгыгыз, аннары шакмаклар янындагы түгәрәккә рәсемнең тәртип санын куегыз. «Салават күпере»н сездән соң укыган кеше буталырлык булмасын!

Рәссам Л. ЗОЛОНДИНОВА

КИКРИКҖАН БЕЛӘН БҮРТӘЙ МАҖАРАЛАРЫ


(Дәвамы. Башы 8 нче санда).















-К...к...к...КЕМ с...с...с...СИН?



-МИН КЕРПЕ МАЛАЕ Энәкәй !



-БЕЗ СИНЕ ТУП ДИП УЙЛАДЫК. ГАФУ ИТ ИНДЕ....


-Нишләп йөрисең монда, Энәкәй ?
-УРМАН БАЗАРЫНА БАРА ИДЕМ. АЛМА АЛЫРГА.


-Ә БЕЗ ТӨЛКЕ ТОТАРГА БАРАБЫЗ.


-САК ЙӨРЕГЕЗ !


-Ашыйсы килгән иде,.. Әйбәт булды әле бу.
-Минем дә карын ачты.


Ба..а..бах!!
БУМ!


-Ай!..ай!..ай!..
-Бе..без кайда?
(Дәвамы киләсе санда)



Идел суы ага торыр...



Идел буенда, болгарлар күчеп килгәнче үк, башка төрки кабиләләр һәм хәзерге мариларның, удмуртларның, чуашларның, мордваларның бабалары яшәгән. Болгарларны монда беркем дә кочак җәеп каршы алмаган, билгеле. Ләкин болгарлар мондагы халыклардан аерылып торганнар, алар тиз арада Идел буенда үз дәүләтләрен төзи башлаганнар, сәүдә эшен җайга салганнар. Бераздан монда яшәгән төрки һәм фин-угор кабиләләре болгарларга буйсына башлаган. Идел буенда төзелгән дәүләтне дә Бөек Болгар дип атаганнар.

Чыннан да бөек дип әйтерлеге булган шул аның!

Бер-бер артлы монда зур шәһәрләр калкып чыккан: Болгар, Биләр, Суар, Кашан, Җүкәтау, Ашлы...

Болгарлар Европада беренче булып чуен кою серенә төшенгәннәр. Безнең бабайлар, шулай ук беренчеләрдән булып, акча суга башлаганнар, алтын-көмеш тәңкәләргә болгар бизәкләре төшкән.

Сәүдәгәрләр төрле илләрдән затлы маллар алып кайткан, болгарларның үзләрендә дә чит ил халыкларын кызыктырырлык тауарлар бихисап булган. Болгар күннәре бөтен дөньяда дан казанган, болгари итекләр кию затлылык, дәрәҗә билгесе саналган.

Болгарга кәрваннар агылган. Алар үзләре белән тауар гына түгел, китаплар да алып килгәннәр. Мөселман илләреннән килгән сәүдәгәрләр болгарларга үз диннәрен мактаганнар: аракы эчү — гөнаһ, тәмәке тарту — гөнаһ!.. Моңардан да яхшы тагын нинди дин бар? «Юк!»— дигән болгарларның байтагы һәм ислам диненә күчкәннәр. Алар салган мәчеттән иртә-кич моңлы азан тавышы яңгыраган.

Шәһәрләрдә мунчалар гөрләп эшләгән. Алар юыну-чистарыну урыны гына түгел, ял итү урыны да булган. Анда шахмат уйнаганнар, бәхәсләшкәннәр, шигырьләр тыңлаганнар. Болгар шагыйренең мәгърур тавышы һаман да безнең колакларда чыңлый сыман әле!

Идел суы ага торыр,
Кыя төбен кага торыр...



Рәссам Р. ШӘМСЕТДИН

Нәҗип Сибгатулла улы Тахтамышев Аксубай районы Яңа Дума авылында 1883 елда туа. Шул авыл мәктәбендә, аннары Казанда укый.

Балалар өчен күп кенә әсәрләр иҗат итә. 1933 елда вафат була.

Нәҗип Думави

Беренче кар

Рәссам Р. Сиражетдинов

Төн буенча туктамастан
Тышта ап-ак кар ява.
Капланып кырлар, болыннар,
Җир йөзе ап-аклана.
Ниндәен тиз үзгәреш бу!
Ниндәен тиз алмашу!—
Арба урынында бүген
кошлар кебек чана чаба.
Күрмәссең тышта яланбаш
Һәм ялан өс бер кеше,
Чөнки тышта салкын, суык,—
Аннан адәмнәр саклана.
«Кыш та җитте, нишлиек,
Кайда барыйк»,— дип,
кош вә корт
Кайгыра да кайгыра,
Кышкы суыктан зарлана.
Зарлана кош-корт вә ләкин
Шул вакыт бер яшь бала,
Йокысыннан уянып,
Тышка таба күзне сала.
«Кар явадыр, кыш була!»— дип
Кычкыра ул яшь бала;
Үз-үзен белми куана,
Кул чаба да шатлана!

әниләргә
һәм
нәниләргә

БАЛА УЯНГАЧ

Үчти-үчти, үчтеки,
Үсмәгәнгә кечтеки.
Үскәчтен ул зур булыр,
Зур булгачтын туй
булыр.

Үчти-үчти, үчтеки,
Үсмәгәнгә кечтеки.
Үсә-үсә зур булыр,
Бигрәк матур кыз
булыр,
Илдә-җирдә бер
булыр.
Үчтеки!



Салават күпере

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ИДАРӘСЕ һәм ВЛКСМның ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКА КОМИТЕТЫНЫҢ НӘНИЛӘР ӨЧЕН АЙЛЫК ЖУРНАЛЫ
1990 ЕЛНЫҢ МАРТ АЕННАН ЧЫГА

БАШ МӨХӘРРИР
Зиннур ХӨСНИЯР

ИДАРӘ

Шәүкәт ГАЛИЕВ,
Фирая БӘДРЕТДИНОВА (җаваплы сәркатип),
Ләбиб ЛЕРОН (бүлек мөхәррире),
Роберт МИҢНУЛЛИН,
Ринат МӨХӘММӘДИЕВ,
Солтан СӘЛИМҖАНОВ,
Мәгъсум ХУҖИН,
Фәридә ХӘСЬЯНОВА,
Мәсгудә ШӘМСЕТДИНОВА,
Асия ЯРУЛЛИНА

Бизәлеш мөхәррире
Айдар ҮТӘГӘН

Тышлыкта
Ю. ДЕНИСОВ рәсеме

КПССның Татарстан республика комитеты нәшрияты
Казан, Декабристлар урамы, 2.

«Салават күпере» ежемесячный журнал Правления Союза писателей ТССР и Татарского РК ВЛКСМ для малышей.
Издается при участии Советско-Финской фирмы «ПОИНТ» (на татарском языке). Основан в 1990 году.
Адрес редакции:
420012, г. Казань, ул. Комлева, 14. Редакция журнала «Салават күпере».

Производствога бирелде 03.09.90 ел.
Басарга кул куелды 15.11.90 ел.
Кәгазь форматы 84×108 1/16. Басма табак 1,0 (2,1). Учет. издат. табак 3,09. Офсет ысулы белән басыла.
Тиражы — 24044. Заказ Д-416.
Бәясе 50 тиен.



Дәү әнидә кунакта

Җәвад Тәрҗеман

Җәй көне булдым авылда,
Дәү әнидә кунакта.
Татарча сөйли белергә
Өйрәндем мин шул чакта.

Өйрәнмичә булмый анда,
Русча берни белмиләр.
Әллә уйнап, әллә чынлап:
«По-русски не знай»,— диләр.

Тавыклар да, үрдәкләр дә
«Күш-шай!»— дисәң, качалар.
«Аша»,— дисәң, авызларын
Бик зур итеп ачалар.

Сөтләре дә, каймагы да
Бөтенләй башка анда;
Авылда дәү әниләрдә
Торсаң иде һаман да.

Киләсе җәйдә әннәм дә,
Әттәм дә барып әле
Һәм татарча сөйләшергә
Өйрәнеп кайтыр әле.



Бәясе 50 тиен.